ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15 июля 2016 г.**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 1839**

Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Солнечная ур., 36 йорт адресы буенча җир кишәрлеген алу турында

Зеленодольск муниципал районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 26.09.2013 ел, №2178 карары белән расланган «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 21.07.2007 ел, №185-ФЗ Федераль закон нигезендә 2013-2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатларында һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турындагы карарга нигезләнеп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты
**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Солнечная урамы, 36 йорт адресы буенча җир кишәрлеген, анда Солнечная урамындагы 36 нчы номерлы авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы торак йорт, шулай ук әлеге йортта урнашкан күчемсез милек объектларын (торак һәм торак булмаган бүлмәләр), шул исемлек нигезендә алырга. (Кушымта бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм “Зеленодольская правда" газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:
   - чыгарыла торган күчемсез милекнең хокук ияләренә;
   - күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;
   - МКУ "Торак сәясәте департаменты”на җибәрергә.
4. МУ «Зеленодольск муниципаль районы җир мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А. В. Старостин

2016 елның 15 июлендәге 1839 нче номерлы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет карарына кушымта

Шәһәр тибындагы Васильево поселогында урнашкан
Солнечная урамы,
36 нчы номерлы күпфатирлы торак йортта урнашкан,
ашыгыч һәм сүтелергә тиешле дип танылган күчемсез
милек объектының Исемлеге

| кв. № | Объектның кадастр (яки) шартлы номеры |
|---|---|
| 1 | 16:20:010151:303 |